ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 12 февраля 2016 г. г. Казань № 35

**Коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийлар системасын урнаштыру турында**

«Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ санлы Федераль законга, «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя кую нигезләре һәм тарифларны, өстәлмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан җайга салынучы коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийлар системасын әлеге боерык кушымтасына туры китереп урнаштырырга.
2. Файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен тәгаенләнгән критерийлар системасы коммуналь комплекс оешмаларының җитештерү программаларын килештергәндә һәм әлеге оешмаларның хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләгәндә, шулай ук коммуналь комплекс оешмаларының эшчәнлек шартлары объектив үзгәрешләргә дучар булган очракта, күрсәтелгән оешмаларның хезмәт күрсәтүләренә тарифлар вакытыннан алда яңадан каралганда кулланыла дип билгеләргә.
3. Коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файда-ланучылар өчен файдалану мөмкинлеген анализлау каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү өчен файдаланылган коммуналь инфраструктура системаларын эксплуатацияләгән коммуналь комплекс оешмаларына карата башкарыла.
4. Коммуналь комплекс оешмаларының хезмәт күрсәтүләренә тарифлар коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучылар мәнфәгатьләренең, кулланучылар өчен әлеге хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген һәм коммуналь комплекс оешмаларының нәтиҗәле эш башкаруын

тээмин итүче коммуналь комплекс оешмалар мәнфәгатьләренең балансына ирешүне тәэмин итәргә тиеш.

5. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файда-ланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийлар системасын урнаштыру турында» 2015 елның 24 февралендәге 44-а санлы боерыгы үз көчен югалткан дип санарга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

7. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисе урынбасары Л.П.Борисовага йөкләргә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты боерыгына 2016 елның 8 февралендәге 31 санлы кушымта

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан җайга салынучы коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийлар системасы

1. Коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән физик яктан файдалану мөмкинлеге.

Физик яктан файдалану мөмкинлеге критериесе коммуналь комплекс оешмаларының җитештерү программалары нигезендә кулланучылар өчен хезмәт күрсәтүләрнең таләп ителгән күләмен тәэмин итүне билгели.

2. Коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән икътисадый яктан файдалану мөмкинлеге.

Кулланучылар өчен икътисадый яктан файдалану мөмкинлеге критериесе кулланучыларның хезмәт күрсәтү бәяләрен түли алу мөмкинлеген яктырта.

Хезмәт күрсәтүләрдән икътисадый яктан файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен хезмәт күрсәтүләргә тарифлар үзгәреше динамикасы коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләренә федераль һәм региональ дәрәҗәдә билгеләнгән тарифларның максималь үзгәрү мөмкинлегенең чик индексларына туры китерү нигезендә бәяләнә.